| | |
|---|---|
| **СОВЕТ**<br>**Кичкетанского сельского поселения**<br>**Агрызского муниципального района**<br>**Республики Татарстан** | **Татарстан Республикасы**<br>**Әгерҗе муниципаль районы**<br>**Кичкетан авыл җирлеге**<br>**СОВЕТЫ** |
| **РЕШЕНИЕ** | **КАРАР** |

28.08.2018 Кичкетан авылы № 45-2

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кичкетан авыл җирлеге Советы Карары 16 апрель 2018 ел № 40-1 белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы “Кичкетан авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге милкендә булган, өченче зат хокукларыннан азат (кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының милек хокукларыннан тыш) кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын яклау инфраструк-турасын булдырган оешмаларга биләмәгә һәм (йә) куллануга тапшыру өчен билгеләнгән муниципаль милек (җир участокларыннан тыш) исемлеген формалаштыру, алып бару һәм бастыру Тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында ”гы Федераль законның 6 октябрь 2003 ел №131-ФЗ 15 маддәсенә, “Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында”гы Федераль законның 24 июль 2007 ел №209-ФЗ 18 маддәсенә, “Россия Федерациясенең дәүләт йә муниципаль милектә булган һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан арендалаган күчемсез милекне тартып алу үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында”гы Федераль законга 22 июль 2008 ел №159-ФЗ, “Көндәшлекне яклау турында”гы Федераль законга 26 июль 2006 ел №135-ФЗ туры китереп, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кичкетан авыл җирлеге Советы к а р а р б и р д е:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кичкетан авыл җирлеге Советы Карары 16 апрель 2018 ел № 40-1 белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы “Кичкетан авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге милкендә булган, өченче зат хокукларыннан азат (кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары милек хокукларыннан тыш), кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын булдырган оешмаларга биләмәгә һәм (йә) куллануга тапшыру өчен билгеләнгән муниципаль милек (җир участокларыннан тыш) исемлеген формалаштыру, алып бару һәм бастыру Тәртибенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1)1.3 частен түбәндәге редакциядә язарга:

“1.3. Әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән исемлеккә кертелгән муниципаль милекне сату тыела, “Россия Федерациясенең дәүләт йә муниципаль милектә булган һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан арендалаган күчемсез милекне тартып алу үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында”гы Федераль законга 22 июль 2008 ел №159-ФЗ тәңгәл китереп, андый милекне кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары милкенә түләп алудан һәм Россия Федерациясе Җир кодексының 39-3 маддәсе 2 пункты 6, 8, 9 подпунктлары күрсәтелгән очраклардан тыш. Әлеге милеккә карата шулай ук куллану шартларына ташлама ясау, куллану хокукларын залогка бирү, андый милек белән куллану хокукларын башка хуҗалык эшчәнлеге субъектларының устав капиталына тапшыру, аренда килешүе буенча хокук һәм йөкләмәләрне өченче затка тапшыру, субарендага тапшыру, кече һәм урта эшмәкәрлекне яклау инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмалар тарафыннан кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына субарендага бирүдән, “ Көндәшлекне яклау турында”гы Федераль законның 26 июль 2006 ел №135-ФЗ 17-1 маддәсе 1 часте 14 пунктында каралган милекне субарендага бирү очрагыннан тыш, әлеге милекне субарендага бирү тыела.

2. Әлеге Карарны Кичкетан авылы җирлеге мәгълүмат стендларына, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр порталы составындагы Әгерҗе муниципаль районы сайтына http://agryz.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы хокукый информация рәсми порталына http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге Карарны үтәүгә контрольне үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе З.Р.НУРИЕВ